КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 сентябрь г.Казань № 873

Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар үткәрүгә бәйле булган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карары үз көчен югалткан дип санарга:

«Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 28 май, 381 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль

юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 28 май, 381 нче карары белән расланган Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2017 ел, 15 ноябрь, 880 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 28 май, 381 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 14 апрель, 248 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 май, 381 нче карары белән расланган Физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар, мәдәни-массакүләм чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге бүтән чаралар үткәрү белән бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 11 июнь, 446 нчы.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына йөкләргә.

4. Бу карарның гамәле 2018 елның 22 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин